**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы**
**Азнакай район Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 88-11 «26» октябрь 2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2017 елның 20 июнендәге 116-19 номерлы «Муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга), урамнарга, скверларга, мәйданнарга исемнәр бирү турындагы нигезләмә хакында» карары белән, Азнакай муниципаль районы территориясендә гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатларында аларның исемнәрен үзгәртү тәртибендә расланган, гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатларында муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга), урамнарга, скверларга, мәйданнарга исемнәр бирү турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021елның 30 июнендәге ТГ-П16-8721 (№22) номерлы хаты нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар итә:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2017 елның 20 июнендәге 116-19 номерлы «Муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга), урамнарга, скверларга, мәйданнарга исемнәр бирү турындагы нигезләмә хакында» карары белән, Азнакай муниципаль районы территориясендә гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатларында аларның исемнәрен үзгәртү тәртибендә расланган, гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү максатларында муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга), урамнарга, скверларга, мәйданнарга исемнәр бирү турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле сигезенче абзацны өстәргә:

«1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы геройлары, үлем көненнән алып 3 елдан да артык булмаган вакыт узгач.».

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru. һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Азнакай район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләнә.

Рәис М. З. Шәйдуллин